БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26 июль 2018 ел № 140

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 7 октябрендәге 75-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 23 декабрендәге 99-ТРЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставының 85, 86, 87 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2016 елның 28 апрелендәге 37 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 6 статьяның 1 өлешендәге 31 пунктына «(волонтерлыкка) сүзен өстәргә;»;

1.2. 6 статьяның 1 өлешендәге 32 пунктын төшереп калдырырга;

1.3. 7 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыру, шулай ук ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллану һәм федераль законнар нигезендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрү;»;

1.4. 7 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

12) инвалидлар, мөмкинлекләре чикләнгән затлар физик культурасын һәм спортын, адаптив физик культураны һәм адаптив спортны үстерүгә ярдәм күрсәтү.»;

1.5. 17 статьяның исеме яңа редакциядә бәян итәргә:
«17 статья. Гавами тыңлаулар, җәмәгать фикер алышулары»;

1.6. 17 статьяның 3 өлешендәге 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт өстәргә:

«2.1) Районның социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проекты;»;

1.7. 17 статьяның 3 өлешендәге 3 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

1.8. 17 статьяга түбәндәге эчтәлекле 12 өлеш өстәргә:

«12. Территорияне планлаштыру проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан территорияне межалау проектлары, җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турында карарлар проектлары, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында карар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең расланмаган булганда, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның рөхсәт ителгән төреннән башка төренә үзгәртү мәсьәләләре буенча җәмәгать фикер алышулары яисә гавами тыңлаулар үткәрелә, аларны оештыру һәм үткәрү тәртибе шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында закон нигезләмәләрен исәпкә алып, Район Советы тарафыннан норматив хокукый акт белән билгеләнә.»;

1.9. 17 статьяның 10 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге статьяда күрсәтелгән мәсьәләләр буенча проектлар һәм гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе Район Советы тарафыннан расланган Гавами тыңлаулар турында нигезләмә белән билгеләнә.»;

1.10. 29 статьяның 1 өлешендәге 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) Районның социаль – икътисади үсеш стратегиясен раслау;

1.11. 39 статьяның 3 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Район башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, Район Советы тарафыннан үз составыннан сайланучы район башлыгын сайлау әлеге вәкаләтләр туктатылган көннән алып алты айдан да соңга калмыйча башкарыла.

Шул ук вакытта, әгәр Район Советы вәкаләтләре вакыты чыкканчы алты айдан да ким вакыт калса, Район Башлыгын яңа сайланган Район Советы составыннан сайлау Район Советының беренче утырышында гамәлгә ашырыла.»;

1.12. 39 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«4. Әгәр Татарстан Республикасы Президентының Район Башлыгы вазыйфасыннан читләштерү турында хокукый акты нигезендә яисә Район Советының Район Башлыгын отставкага җибәрү турында карары нигезендә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган Район Башлыгы әлеге хокукый актка яки карага суд тәртибендә карарга шикаять бирсә, Район Советы үз составыннан Район Советы тарафыннан сайлана торган Район Башлыгын сайлау турында карар кабул итәргә хокуклы түгел.»;

1.13. 40 статьяның 3 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Район Башлыгы урынбасары Район Советы регламентында билгеләнгән вазыйфалар бүленеше буенча Район Башлыгы йөкләмәләрен үти, ә вакытлыча булмаганда (авыру яки отпуск белән бәйле рәвештә), үз бурычларын үти алмаса, вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатканда, суд карары буенча сак астына алу яки вазыйфадан вакытлыча азат итү рәвешендә процессуаль мәҗбүр итүне кулланганда, Район Башлыгы урынбасары вакытлыча Район Башлыгы вәкаләтләрен башкара.»;

1.14. 43 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктының 6 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Районның социаль-икътисади үсеш стратегиясен эшли һәм тормышка ашыра»;

1.15. 43 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктның 7 абзацында «-Район бюджетын үтәүне, Районны комплекслы социаль-икътисадый үстерү планнарын һәм программаларын үтәүне оештыра» сүзләрен яңа редакциядә бәян итәргә:

« - район бюджеты үтәлешен оештыра; »;

1.16. 43 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктының 8 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«- Районның социаль-икътисади үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру турында хисаплар әзерләүне тәэмин итә;»;

1.17. 43 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктының 9 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«-Район икътисады һәм социаль өлкәсе торышын характерлый торган статистик күрсәткечләр җыюны һәм күрсәтелгән мәгълүматларны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына тапшыруны оештыра;»;

1.18. 43 статьяның 2 өлешендәге 10 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«10) федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыру, шулай ук ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллану һәм федераль законнар нигезендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрү;»;

1.19. 44 статьяның 5 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Район Башкарма комитеты җитәкчесе «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акча һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, бурычларны үтәргә тиеш.»;

1.20. 48 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3) әлеге статьяның 2 яки 2.1 өлеше нигезендә контрактны өзү;»;

1.21. 48 статьяга түбәндәге эчтәлекле 2.1. өлешен өстәргә:

«2.1. Район Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт Татарстан Республикасы Президенты гаризасы нигезендә, коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акча һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәгән, бурычларны үтәмәгән өчен өзелергә мөмкин.»;

1.22. 80 статьяның 1 өлешен «Район халкы» сүзләреннән соң «(Район чикләрендә авылара территориядә урнашкан торак пункты)»;

1.23. 80 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган түләүләрне алып бару һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда, ә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясындагы 1 өлешенең 4 һәм 4.1 пунктларында каралган очракларда гражданнар җыенында хәл ителә.»;

1.24. 87 статьяның 3 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«Район Уставына кертелгән һәм җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр, җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләрне чикләү (Район Уставын федераль законнарга туры китерү, шулай ук җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының вәкаләтләрен, вәкаләтләре вакытларын, аларны сайлау тәртибен үзгәртү очракларыннан тыш), Район Уставына күрсәтелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актны кабул иткән Районның вәкиллекле органы вәкаләтләре чоры узганнан соң, ә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 4 өлешендәге 1 пункты һәм 35 статьясындагы 5 өлешенең 1 пункты нигезендә Районның вәкиллекле органы формалашкан очракта - Район Уставына күрсәтелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актка имза куйган Район Башлыгы вәкаләтләре вакыты тәмамланганнан соң үз көченә керә.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Әлеге карар, гамәлдәге законнарда үз көченә керүнең башка вакытлары каралган нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

4. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары Н.Н.Сабирҗановка йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин